ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Кукмара муниципаль районы
Күкшел авыл җирлеге Советы

# КАРАР

2020 елның 28 гыйнвары 3 нче номерлы

Күкшел авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 32 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Күкшел авыл җирлеге карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2013 елның 13 нче ноябрендәге Күкшел авыл җирлеге Советының 28 номерлы карарына (Күкшел авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 36 номерлы, 2015 елның 29 маендагы 27 номерлы, 2015 елның 26 ноябрендәге 14 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 11 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 34 номерлы, 2018 елның 20 декаберендәге 35 номерлы, 2019 елның 28 ноябрендәге 19 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) кадастр хакының 0,1% ы – 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: www.pravo.tatarstan.ru, шулай ук Күкшел авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында да.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

Күкшел авыл җирлеге
башлыгы: Рәхимуллин И.Т.